


22 апрельдә ботен донья Жир конен билгеләп vттек планетабызнын зәгыйфьлеген һәм ана сакчыл монәсәбәт кирәклеген искә тошерде.
Кешенен табигатькә контрольсез йогынтысы кискен ноктага житкән һәм глобаль һәлакәт белән яный. Жыелган капкачлар, яна файдалы предметларга әверелеп, икенче тормыш алачак. Куркыныч матдәләр булган батареялар чvплеккә эләкмәячәк, чонки мәктәпләребездә, китапханәләрдә тирә-як моһитенә сак булуны тәрбиялиләр, туфрак һәм сунын пычрануын булдырмаска тырышалар. Мәсәлән, Темников районы Митрял авыл китапханәсендә аз билгеле, ләкин бик моһим бәйрәмгә – Ботендонья Жир коненә багышланган «Бу планетада мина һәм сина яшәргә» эко-сәгатьне Венера Рәшит кызы Ялышева vткәргән һәм барлык проблемалар турында сойләгән.